РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«17» апрель 2020 ел Олы Кайбыч ав. № 231

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының 2019 елның 14 февралендәге 150 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 15 п., Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына «Челтәр компаниясе» ААҖ энергетика объектларын чагылдыру өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның февралендәге 150 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1,2,3 пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. «Кайбыч муниципаль районын территориаль планлаштыру схемасын раслау турында» 2014 елның 26 маендагы 221 номерлы Кайбыч муниципаль районы Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына муниципаль районны электр белән тәэмин итү картасын нигезләү материалларын әзерләү һәм тулыландыру өлешендә үзгәрешләр кертергә.

2. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Территориаль планлаштыру схемасына муниципаль районны электр белән тәэмин итү картасын нигезләү материалларын эшләү һәм тулыландыру өлешендә үзгәрешләр кертү буенча чаралар планын, чараларны үтәү срокларын расларга (кушымта).

3. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Территориаль планлаштыру схемасына муниципаль районны электр белән тәэмин итү картасын нигезләү материалларын әзерләү һәм тулыландыру өлешендә үзгәрешләр кертү эшләрен финанслау «Челтәр компаниясе» ААҖ акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.»

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга, Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://kaybici.tatarstan.ru).

Совет Рәисе А.И.Рәхмәтуллин